КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 июль г.Казань № 659

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин